ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» февраль 2023 ел № 34

Торак биналарны алу турында

Татарстан Республикасы, Әгерҗе шәһәре, Ленин урамы, 35А йорты адресы буенча урнашкан күпфатирлы йортларны яшәү өчен яраксыз дип тану уңаеннан һәм Россия Федерациясе Торак кодексы, “Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү фонды турында” 21.07.2007 елның 185-ФЗ номерлы Федераль законы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 елның 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен тиешле җир кишәрлекләрен алуга бәйле рәвештә милек хокукында булган һәм сатып алынырга тиешле күпфатирлы йортларда торак урыннары исемлеген расларга:
- ТР, Әгерҗе шәһәре, Ленин урамы, 35А йорты, кв. 1;
- ТР, Әгерҗе шәһәре, Ленин урамы, 35А йорты, кв. 2;
- ТР, Әгерҗе шәһәре, Ленин урамы, 35А йорты кв. 7;

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының Торак сәясәте һәм торак-коммуналь хуҗалыгы секторына:
- торак урыннарны сатып алу шартнамәләре проектларын әзерләргә;
- әлеге карарның күчермәсен күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш бирешләрне Бердәм дәүләт реестрына алу турында язма кертү өчен Татарстан Республикасы буенча Росреестр идарәсенең Әгерҗе бүлегенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкче урынбасары** **К.М.Сотов**